**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы
**КАРАРы**

2023 елның 12 мае №22 Урыссу ш.т.п.
,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклап калу һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы, миграция вазгыяте турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 июлендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» Россия Федерациясе Президентының 19.12.2012 № 1666 Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 03.07.2008 № ПУ-312 Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» 26.07.2013 № ПУ-695 Указы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы Р.Р. Абдурахмановның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы, миграция вазгыяте турында» докладын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклап калу һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы, миграция вазгыяте турында» докладны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр башлыкларына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, миграция вазгыятен алга таба ныгыту чараларын күрүне тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы оешмаларына һәм учреждениеләренә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, миграция вазгыятен ныгыту чараларын гамәлгә ашыруда актив катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Ютазы район Советы комиссиясе Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, миграция вазгыяте өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында "Рәсми Татарстан" дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район
Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин